РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» февраль 2023 ел г. Альметьевск № 211

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2020 елның 9 декабрендәге 1800 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2020 елның 9 декабрендәге 1800 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 07 февралендәге 158 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 2450 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1.1 Программа паспортының «Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» төзелешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалары исәбеннән 1383,295 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны гамәлгә ашыру еллары буенча:<br>2021 ел - 276,45 мең сум;<br>2022 ел - 676,845 мең сум;<br>2023 ел - 430,0 мең сум.<br><br>Искәрмә: *Финанслау күләме фаразлау характерында һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне җайга салу» 4 бүлегенең 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалары исәбеннән 1383,295 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны гамәлгә

Зак. № 305-2000

ашыру еллары буенча да:

2021 ел - 276,45 мең сум;

2022 ел - 676,845 мең сум;

2023 ел - 430,0 мең сум.».

1.3. 2021-2023 елларга Әлмәт муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программага кушымтада:

1 бүлекнең 1.21 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.21. Криминаль актларының комплекслы экспертизасын финанслау экстремизм күренешләре | ТР ӘМР башкарма комитеты | 2021-2023 | 1316,391 ӘМР бюджеты | 254,2 | 662,191 | 400,0» |

«Шәһәрнең югары һәм урта уку йортлары студентлары һәм эшләүче яшьләр арасында түгәрәк өстәлләр, фестивальләр, халык бәйрәмнәре, акцияләр, квестлар, ишегалды бәйрәмнәре үткәрү» 1 бүлегенең 2.8 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.8. Шәһәрнең югары һәм урта уку йортлары студентлары һәм эшләүче яшьләр арасында түгәрәк өстәлләр, фестивальләр, халык бәйрәмнәре, акцияләр, квестлар, ишегалды бәйрәмнәре үткәрү | УДДМ АМР РТ | Ай саен хисап кварталыннан соң киләторган айның 10 числосына кадәр хисап | 66,904 ӘМР бюджеты | 22,25 | 14,654 | 30,0 |

«Программа буенча барысы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Программа буенча барысы: | | | 1383,295 | 276,45 | 676,845 | 430,0» |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов